ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**07.12.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2502**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2017 елның 25 июлендәге 2029 номерлы карарының кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 30 декабрендәге 1096 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 13 ноябрендәге 996 номерлы карарын (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 25 июлендәге 546 номерлы, 2016 елның 8 февралендәге 76 номерлы, 2017 елның 31 мартындагы 201 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2029 номерлы карары кушымтасына (Зеленодольск муниципаль районының 2017 елның 13 октябрендәге 2595 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативларын исәпләп чыгару буенча:

2 бүлектә:

2.7 пунктының унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карары нигезендә тәрбиячеләрнең база оклады (хезмәт хакы ставкасы) аттестацияне уңышлы

узган затка "бакалавр", "магистр" яки "дипломлы белгеч" квалификациясен үзләштерүне раслый торган югары һөнәри белемле вазыйфаның база окладына туры килә»;

2.9 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«FOT^{i}_{vosvz} = \frac{\left(y \times x \times \left(1/n_{vs\,восп} \times b_{восп}\right) \times e \times k_{v\,восп} \times 12 + y \times x / n_{vs\,восп} \times D_{sm}\right)}{m_{vzqlin}} \text{ x } (1+К_{замещ}),»;$$

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$D_{sm}$ - Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карары нигезендә авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләү күләме;»;

унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2.10 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карары нигезендә педагог-психологларның база оклады (хезмәт хакы ставкасы) аттестацияне уңышлы узган затка "бакалавр", "магистр" яки "дипломлы белгеч" квалификациясен үзләштерүне раслый торган югары һөнәри белемле вазыйфаның база окладына туры килә»;

2.12 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«FOT^{i}_{ppsvzq} = n_{vzqpps} \times b_{pps} \times e \times k_{vpps} \times 12 + (n_{vzqpps} \times D_{sm} \times e \times 12),»;$$

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$D_{sm}$ - Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карары нигезендә авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләү күләме;»;

тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2.13 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карары нигезендә башка педагогик персоналның база оклады (хезмәт хакы ставкасы) аттестацияне уңышлы узган затка "бакалавр", "магистр" яки "дипломлы белгеч" квалификациясен үзләштерүне раслый торган югары һөнәри белемле вазыйфаның база окладына туры килә»;

2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.15. Башка педагогик персоналның хезмәт хакы фонды башка педагогик персоналның хезмәт хакы фондына түләүләре белән түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$«FOT^{i}_{pedvz} = (a_{Z1}/z_1 + a_{Z2}/z_2 + a_{Z3}/z_3) \times b^{t}_{v} \times e \times k_{v} \times 12 + (a_{Z1}/z_1 + a_{Z2}/z_2 + a_{Z3}/z_3) \times D_{sm} \times e \times 12,»;$$

биредә:

«$FOT^{i}_{pedvz}$ - башка педагогик персоналның хезмәт хакы фонды һәм башка педагогик персоналның хезмәт хакы фондына түләүләр;

$a_{z1}$ - физкультура-сәламәтләндерү циклы дәресләре буенча мәктәпкәчә яшьтәге балаларның атналык белем бирү йөкләнеше сәгатьләре саны, 3 нче таблицада каралганча ;

$a_{z2}$ - эстетика циклы дәресләре буенча мәктәпкәчә яшьтәге балаларның атналык белем бирү йөкләнеше сәгатьләре саны, 3 нче таблицада каралганча ;

$a_{z3}$- балаларның танып-белү активлыгын һәм акыл киеренкелеген арттыруны таләп итә торган дәресләр буенча мәктәпкәчә яшьтәге балаларның атналык белем бирү йөкләнеше саны, 3 нче таблицада каралганча ;

3 нче таблица

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында шөгыльләнү төрләре буенча мәктәпкәчә яшьтәге балаларның атналык белем бирү күләменең сәгатьләре саны

(1 укучыга сәгать)

| Шөгыль төрләре | Балаларның атналык белем бирү күләменең астрономик сәгатьләр саны | |
|---|---|---|
| | 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән артык |
| Физкультура-сәламәтләндерү циклы шөгыльләре | 0,050 | 0,125 |
| Эстетика циклы шөгыльләре | 0,050 | 0,142 |
| Балаларның танып-белү активлыгын һәм акыл киеренкелеген арттыруны таләп итә торган шөгыльләр | 0,050 | 0,190 |

$z_1$ - физкультура-сәламәтләндерү циклы укытучыларының хезмәт хакы ставкасы өчен сәгать саны (атнага 30 сәгать);

$z_2$ - эстетика циклы укытучыларының хезмәт хакы ставкасы өчен сәгать саны (атнага 24 сәгать);

$z_3$ - балаларның танып-белү активлыгын һәм акыл киеренкелеген арттыруны таләп итә торган шөгыльләр буенча тәрбиячеләрнең хезмәт хакы

ставкасы өчен сәгать саны (атнага 36 сәгать);

$b_v^t$ - шәһәр һәм авыл җирлекләрендә мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча дүрт разрядлы тариф челтәренең IV разряды буенча хезмәт хакы ставкасы, ул 2.13 пункты нигезендә кабул ителә;

е-законнар нигезендә иминият кертемнәре күләме;

$k_v$ - педагогик хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүнең тарифтан тыш фондының 2.14 пункты нигезендә кабул ителә торган коэффициенты;

«$D_{sm}$ - Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карары нигезендә авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләү күләме;

12 - елга айлар саны.»;

2.16 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карары нигезендә башка педагогик персоналның база оклады (хезмәт хакы ставкасы) аттестацияне уңышлы узган затка "бакалавр", "магистр" яки "дипломлы белгеч" квалификациясен үзләштерүне раслый торган югары һөнәри белемле вазыйфаның база окладына туры килә»;

2.18 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$FOT_{cvznc}^{t} = s_{vz} \times b_v \times e \times k_v \times 12 + s_{vz} \times D_{sm} \times e \times 12$,»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$D_{sm}$ - Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карары нигезендә авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләү күләме;»;

унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

күрсәтелгән карар белән расланган Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләп чыгару буенча:

исемендә «күрсәтүгә» сүзләреннән соң «муниципаль» сүзен өстәргә;

1 бүлекнең 1.2 пунктында «күрсәтүгә» сүзләреннән соң «муниципаль» сүзен өстәргә;

2 бүлектә:

исемендә «күрсәтүгә» сүзләреннән соң «муниципаль» сүзен өстәргә;

2.6 пунктының уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карары нигезендә, төп гомуми белемле, урта гомуми белемле база хезмәт хакына туры килгән

тәрбияче ярдәмчеләренең хезмәт хакы ставкалары.»;

2.15 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карары нигезендә, квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белемле, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белемле, тулы булмаган югары белемле вазифасының база окладына туры килгән урта медицина персоналының хезмәт хакы ставкалары»;

2.17 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«FOT^{t}_{vzq\ mo\ oc} = (n_{vzq\ mo\ sr} \times b_{mo\ sr}) \times e \times k_{v\ mo,vcp} \times 12 + (n_{vzq\ mo\ sr} \times D_{sm} \times e \times 12,»;$$

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$D_{sm}$ - Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карары нигезендә авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләү күләме;»;

2.18 пунктының бишенче абзацында «Зеленодольск муниципаль районының 2014 елның 20 гыйнварындагы 45 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри-квалификация төркемнәренең» сүзләрен «Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы мәгариф оешмаларының гомумтармак һөнәрләре эшчеләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре , җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре» сүзләренә алмаштырырга;».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 1 сентябреннән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С.Анисимовка әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы . А.В.Старостин